ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ялгыз яши торган эшләмәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә, шулай ук бергә яши торган пенсия яшендәге эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $8^3$ статья өстәргә:

«$8^3$ статья. **Ялгыз яши торган эшләмәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә, шулай ук бергә яши торган пенсия яшендәге эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары**

1. Ялгыз яши торган эшләмәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә, шулай ук бергә яши торган пенсия яшендәге эшләмәүче гражданнардан гына (60 яшькә җиткән ир-атлар һәм 55 яшькә җиткән хатын-кызлар) гыйбарәт гаилә составында яшәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертем түләү чыгымнарына, торак урынның гомуми мәйданы бер квадрат метрына капиталь ремонт өчен бер айга кертемнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән минималь күләменнән һәм торак урын белән коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидияләрне исәпләү өчен кулланыла торган торак урынның норматив мәйданы төбәк стандарты чикләрендә аның милкендә булган торак урын мәйданы зурлыгыннан чыгып исәпләнеп, түбәндәге күләмнәрдә компенсация бирелә:

ялгыз яши торган эшләмәүче җитмеш яшькә җиткән торак урыннар милекчеләренә яки бергә яши торган пенсия яшендәге эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче җитмеш яшькә җиткән торак урыннар милекчеләренә – илле процент күләмендә;

ялгыз яши торган эшләмәүче сиксән яшькә җиткән торак урыннар милекчеләренә яки бергә яши торган пенсия яшендәге эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче сиксән яшькә җиткән торак урыннар милекчеләренә – йөз процент күләмендә.

2. Әгәр гражданның әлеге статья нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемне түләү чыгымнарына компенсациягә һәм бер үк вакытта федераль законнар, әлеге Закон яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә башка нигезләр буенча күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертем түләүгә социаль ярдәм чараларына хокукы булса, капиталь ремонт өчен кертем түләүгә компенсация аның әлеге статья нигезендә исәпләнгән күләме һәм федераль законнар, әлеге Закон яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә башка нигезләр буенча капиталь ремонт өчен кертем түләү буенча алынган социаль ярдәм чаралары күләме арасындагы аерма рәвешендә бирелә.»;

3) 9 статьяның 1 пунктында «әлеге Законның 4 – $8^2$ статьяларын» сүзләрен «әлеге Законның 4 – $8^3$ статьяларын» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2018 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 27-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН